УДК 7.067

***Г.С. Мухтарова,***
***А.В. Могильная,***
***А.С. Смагулов***

# КАЗАХСТАНДА КҮРГӘЗМӘ ҺӘМ ГАЛЕРЕЯ ЭШЕ ҮСЕШЕ

Статья посвящена исследованию процесса становления выставочного и галерейного дела в Казахстане. Изучаются виды организации и направлений их деятельности на примере работы государственных и частных музеев и художественных галерей городов Алматы и Астана. Целью статьи является анализ деятельности таких важных институций в развитие изобразительного искусства, как музеи и художественные галереи. Научная новизна заключается в попытке проведения анализа социокультурной динамики развития выставочного и галерейного дела в Казахстане, охватывающий период с 1991 по 2025 годы.

Основные результаты исследования представлены в виде авторской классификации видов галерей, с учетом специфики их деятельности, а также в виде таблицы с названиями и временем открытия галерей, приведенными в хронологическом порядке. Методологической основой представленного исследования являются статический метод, компаративисткий подход, аксиологический анализ.

**Ключевые слова:** галерейное дело, художественная галерея, музей, салон, современное искусство, арт-рынок, выставочная деятельность

The article is devoted to the study of the process of formation of exhibition and gallery business in Kazakhstan. The types of organizations and their areas of activity are studied using the work of public and private museums and art galleries in the cities of Almaty and Astana as an example. The aim of the article is to analyze the activities of such important institutions in the development of fine arts as museums and art galleries.

The scientific novelty lies in the attempt to conduct an analysis of the sociocultural dynamics of the development of exhibition and gallery business in Kazakhstan covering the period from 1991 to 2025.

The main results of the study are presented in the form of the authors classification of gallery types taking into account the specifics of their activities and a data table with the names and opening times of galleries listed in chronological order.

The methodological basic of the presented study is the static method comparative approach and axiological analysis.

**Keywords:** gallery business, art gallery, museum, salon, contemporary art, art market, exhibition activities

Хәзерге заман сәнгате инфраструктурасында күргәзмә-галерея эшчәнлеге актуальлеген югалтмый. Рәссамнарны популярлаштыру, социальләштерү максатыннан күргәзмәләр оештыру өчен музей һәм сәнгать галереяларының махсус күргәзмә киңлекләренә ия булуы бик тә мөһим.

Тасвирый сәнгать өлкәсендә музейлар һәм галереялар әһәмиятле институтлар булып тора. Бүгенге көндә музейлар һәм галереялар тасвирый сәнгатьне тамашачыга тәкъдим итү яки картиналар сату заллары гына түгел инде.

Сәнгать күптән элитарлыгын югалтты, ул күбрәк массачыл мәдәният характерында. Әлеге яссылыкта галереяларның бурычы – билгеле бер максатчан төркемне, сәнгатьне бәяли белүчеләрне һәм белгечләрне колачлау гына түгел, бәлки җәмгыятьнең төрле социаль катлаулары белән бәйләнеш урнаштыру.

Сәнгать галереялары, мәдәният институцияләре кебек үк, социомәдәни арадашчылык формалашуга йогынты ясый. «Выставочное и галерейное дело» китабы авторы Е.А. Карцева болай дип билгеләп үтә: «Социокультурное посредничество способствует установлению связей между художником и публикой, создавая условия для развития, представляя, растолковывая, обращая в той или иной форме внимание зрителя на творчество художника, центральным моментом социализации которого является художественная выставка. Социокультурное посредничество можно разделить на три основные составляющие: исследовательскую (экспертное сообщество: искусствоведы, биографы, критики, кураторы), коммерческую (арт-бизнес, галеристы, дилеры, арт-менеджеры), идеологическую (государственные структуры, чиновники, власть)» [5: 34].

Коммерция эшчәнлегенең бер төре буларак, галерея һәм күргәзмә эше арт-базар белән тыгыз бәйләнгән. Төрле илләрдә галерея эшчәнлеге үзгә сыйфатларга ия. Һәм алар теге яки бу җәмгыятьнең социаль-мәдәни үсешендәге төрле факторларга бәйле. Әмма тасвирый сәнгать әсәрләрен сатып табыш алудан кала, музей һәм галереялар, беренче чиратта, мәдәни-агарту вазифасын да үти. «Бильбао эффекты» феномены – музей рәвешендә төзелгән бер яки берничә әһәмиятле архитектура объектының икътисади һәм социомәдәни яңарыш катализаторына әйләнүенә ачык мисал. Испаниядәге Бильбао шәһәре, 1997 елда Фрэнк Гери проекты буенча Гуггенхайм музее ачылгач, таркалып барган сәнәгать үзәгеннән популяр туризм юнәлешенә әйләнә.

2025 елның сентябрендә Алматы Үзәк Азиядәге мөһим мәдәни тормыш үзәгенә әверелде. Казахстанның бу шәһәрендә берьюлы ике арт-институция ачылды – «Целинный» заманча мәдәният үзәге һәм Almaty Museum of Arts хәзерге заман сәнгате музее. Алар, бергәләп, куәтле мәдәни кластер барлыкка китерәчәк, ул җирле халыкны да, халыкара арт-бергәлекне дә җәлеп итәрдәй яңа үзәк булырга тиеш. 5 сентябрь көнне 1964 елда төзелгән легендар совет кинотеатры бинасында урнашкан «Целинный» заманча мәдәният үзәге тамашачыга үз ишекләрен ачты. Модернизм үрнәге булган тарихи бина җирле архитектор Заура Аитаева һәм Британия архитекторы Асиф Хан бюросы тарафыннан реконструкцияләнде. Команда конструкцияне нытытып кына калмады, ә мирасны сак кына интеграцияләде дә: рәссам

Евгений Сидоркинның югалган дип саналган сграффитолары табылды һәм яңадан торгызылды. Аларның мотивлары корычтан эшләнгән яңа дулкынсыман фасадта чагылыш таба [3].

Алматыдагы «Целинный» заманча мәдәният үзәге «Architectural Record» архитектура журналының (АКШта 1981 елдан бирле чыга) октябрь чыгарылышы тышлыгында бирелә. Үзәк Азия өчен бу сирәк хәл: төбәкнең мәдәни проектлары мондый дәрәҗәдәге басмаларның фокусына еш эләкми. Материалның авторы журналист Эндрю Айрис булды, ул элегрәк Алматыга үзәк ачылышына килгән иде [9].

Музейга нигез салучы, Казахстан эшмәкәре, меценат Нурлан Смагулов Almaty Museum of Arts яңа заманча сәнгать музее ачылышыннан соң, журналистлар белән очрашуда аның Үзәк Азиядә мондый төрдәге иң эре музейларның берсе булуын ассызыклады: «Ул безнең балабыз, бу турыда шәхсән мин үзем 30 елдан артык уйлап йөрдем. Кунаклар арасында бөтен дөньядан килгән институцияләр, музейлар, бу – зур мәртәбә. 80 нән артык халыкара журналист, дөньяда да зур резонанс тудыру. Без хәзер, Франция, Америка, Япония белән беррәттән, ачылышы көтелгән 10 музей исемлегенә керәбез... Бу музей – минем күптәнге хыялымның чынга ашуы. Дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, төрле башкалаларда, мәдәни үзәкләрдә һәм музейларда булганда, безнең шәһәргә менә шундый киңлек җитмәвен аңладым. Алматыга яңа йөз, яңа рух кирәк, без сәнгатьне күрсәтә, үзара очраша алырлык урын кирәк. Биредә сез минем шәхси коллекциямнән сайлап алынган 700 эшне күрерсез» [6].

Мәйданы 10 060 квадрат метр булган бина Британия архитектура бюросы Chapman Taylor тарафыннан проектланды. Аның фасады элеккеге һәм хәзерге материаллардан – борынгы тормыш эзләрен саклаган Юра известьташыннан, анодланган алюминийдан һәм өслеге саклагыч «тере тутык» белән капланган COR-TEN корычыннан эшләнгән. Эчкә кергәнче үк тамашачыларны масштаблы сәнгать әсәрләре каршы ала. Алар арасында унике метрлы «Надэс» скульптурасы (анда испан остасы Жауме Пленса чәчен традицион казах толымнары итеп үргән кызны сурәтләгән) һәм Британия – Нигерия рәссамы Йинка Шонибаре «Җил скульптурасы (ТП) II» – җил белән киерелгән сигез метр биеклегендәге җилкәнне хәтерләткән алюминий композициясен иҗат иткән. Берлин рәссамы Алисия Кваде, Мангыстаудагы «Шарлар үзәне» белән рухланып, музей өчен монументаль «Препозиция» булдырган» [1].

Казахстанда галерея эшчәнлеге тарихы совет чорыннан башлана. Беренче сәнгать галереялары Казахстан Рәссамнар берлеге һәм А. Кастеев исемендәге Дәүләт сәнгать музее материаль базасы нигезендә төзелә.

Бәйсезлек чорыннан башлап, Казахстанда базар икътисады үскән саен, шәхси сәнгать галереялары күпләп ачыла башлый. 1991 елдан алып 2025 елга кадәрге чорда – якынча 35 елны колачлаган вакыт аралыгында республикада галерея эшчәнлеге барлыкка килә

һәм зур үсеш кичерә. Шуңа күрә бу процессны тирәнтен аңларга кирәк.

Казахстанда галерея эшчәнлегенең тарихи-хронологик, институциональ анализын куллану нәтиҗәсендә, республикада галерея эшенең барлыкка килү һәм үсеш процессын анализлап, сәнгать галереялары түбәндәге төркемнәргә бүленә һәм классификацияләнә.

***1. Совет чоры дәүләт мәдәният учреждениеләре базасында ачылган галереялар***

Казахстанда сәнгать күргәзмәләре оештыру һәм сәнгать әсәрләрен сату белән шөгыльләнүче беренче сәнгать салоннары һәм күргәзмә заллары Казахстан Рәссамнар берлеге һәм А. Кастеев исемендәге Дәүләт сәнгать музее базасында төзелә. Боларга түбәндәге күргәзмә мәйданчыклары керә: Алматы шәһәрендәге Рәссамнар йорты вернисажы, А. Кастеев исемендәге ДСМ галереясы, Казахстан Рәссамнар берлегенең Үзәк күргәзмәләр залы. Бу мәйданчыкларда Казахстан рәссамнарының күргәзмәләре уздырыла. Аерым алганда, «Жигер» яшьләр берләшмәсенең республикада юбилейлар һәм истәлекле даталар уңаеннан уздырыла торган күргәзмәләре һ. б.

***2. Мәдәни-агарту характерындагы шәхси сәнгать галереялары***

Казахстанда «Тәңре-Умай» дип исемләнгән беренче шәхси сәнгать галереясы 1992 елның апрелендә Алматы шәһәрендә ачыла. Нәкъ менә әлеге галерея тасвирый сәнгать өлкәсендә ил эчендәге һәм халыкара мәдәни институцияләр арасында диалог урнаштыру максатын күздә тоткан яңа төр галереяга әверелә. Ул Германия халыкара элемтәләр институты, Британия советы, Гёте-институт, Француз альянсы белән партнёрлык проектларын гамәлгә ашыра; төрле вакытта А. Кастеев исемендәге Дәүләт сәнгать музее белән актив хезмәттәшлек итә. 1993 елдан Казахстанда башка шәхси сәнгать галереялары да эшли башлый. Шуларның берсе – «Улар», ул Милли сәнгать академиясенең Галимнәр йорты каршында ачыла. Ул яшь рәссамнар иҗатына булышлык күрсәтүне максат итә.

2013 елда декоратив-гамәли сәнгать әсәрләрен һәм халык промыселлары эшләнмәләрен сатуда махсуслашкан «Assia» галереясы эшли башлый. Галереяның директоры, сәнгать белгече Айжан Беккулова 2003 елда «Our Heritage» (Безнең мирас) фондын оештыра. Аның максаты Казахстанның традицион һәм хәзерге заман гамәли сәнгатенә ярдәм итү һәм аны пропагандалаудан гыйбарәт була. Фонд проектлары кысаларында ел саен «Шебер» һөнәрчеләр конкурсы үткәрелә, шулай ук «Казахстанда һөнәрләрне үстерү һәм халык сәнгать промыселларын торгызу» проекты да уңышлы эшләп килә.

Югарыда санап үтелгән галереяларга нигез салучылар һәм аларның директорлары Владимир Филатов («Тәңре – Умай»), Юрий Маркович («Улар»), Гөлмира Шалабаева («Ою»), Айжан Беккулова («Assia»), Карлыгаш Чубакова («Ак рояль») Казахстанның тасвирый сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертәләр һәм аңа ярдәм итәләр.

***3. Коммерция юнәлешендәге шәхси галереялар***

Соңгы ике дистә елда Казахстанда күпсанлы салон тибындагы галереялар ачыла. Салон тибындагы галерея – ул сәнгать әсәрләрен сату кибете. Бу галереяларның эшчәнлеге коммерция характерында һәм картиналар сатуга юнәлдерелгән. Казахстанда рәсем сәнгате әсәрләрен сату буенча иң борынгы махсуслаштырылган салоннарның берсе – 1986 елда, әле совет чорында ук, Казахстан Республикасы Сәнгать фонды базасында оештырылган «Өнер» сәнгать салоны. Бүгенге көндә дә салон әлеге бизнес белән уңышлы шөгыльләнә.

***4. Тар профильле махсуслаштырылган галереялар***

Әлеге галереяларда тасвирый сәнгатьнең аерым төрләренә юнәлтелгән эш алып барыла. Бу – беренчедән, антиквар әйберләрнең шәхси галереялары. Алар арасында иң өлкәннәре – Азат Акимбәкнең, Мөхәммәтҗан Алибаевның антиквариат салоннары, шулай ук «Антик М» салоны, «Борынгы әйберләр кибете» антиквар салоны һ. б. 2002 елда ачылган «Адем-ай Plus» галереясы шул ук исемдәге компаниянең үз милли сувенир продукциясен сату белән шөгыльләнүче салон-кибет булып тора.

2012 елда ачылган «Җамал» ориенталь сәнгать арт-галереясы, шулай ук 2013 елда төзелгән «Clay house gallery» авторлык керамикасы арт-галереясы кебекләре аеруча тар юнәлешле.

***5. Рәссамнар истәлегенә ачылган галереялар***

Мондый пландагы тәүге галереяларның берсе 1997 елда танылган скульптор истәлегенә ачыла, һәм ул «Рысбәк Әхмәтов галереясы» дип атала, ә 2002 елда Жанатай Шарденов исемендәге «Умай» сәнгать музее ачыла. 2004 елда танылган казах рәссамы Абелхан Кастеевның туган җирендә, Жаркент шәһәрендә «Абелхан Кастеевның сәнгать галереясы» эшли башлый.

***6. Мультимедиа һәм интернет киңлеге галереялары***

Заманча галереяларның популяр төре – мультимедиа киңлеге галереялары. Мәсәлән, 2014 елда Алматы шәһәренең Достык Plaza сәүдә үзәгендә ачылган «360 space Multimedia» галереясы. Биредә «Ван Гогның terелгән картиналары», «Сальвадор Дали», «Арман Алма-Ата» кебек мультимедиа күргәзмәләре узды. Бүгенге көндә интернет мөмкинлекләреннән файдаланучы интернет-галереялар да барлыкка килә. Алар арасында «Тәңре-модерн» интернет-галереясы һ. б. шундыйлардан.

***7. Яңа башкала – Астана шәһәре галереялары***

1997 елдан Астана шәһәре илнең һәм административ, һәм мәдәни үзәге булырга тиеш булганлыктан, яңа башкалада сәнгать галереялары эшли башлый. 2006 елда башкалада беренче шәхси «Куланши» сәнгать галереясы үз ишекләрен ача. Галерея директоры рәссам, Phd докторы Ләйлә Махат Казахстан Республикасының төрле төбәк-

ләрендә яшәп иҗат итүче рәссамнарның күпсанлы күргәзмәләрен оештыра.

2016 елда Форт банкның баш офисында ForteBank Kulanshi ArtSpace галереясы ачыла. Сәнгать үсешенә ярдәм итү, Казахстан Республикасы халкының рухи һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү өчен Fortebank Kulanshi заманча сәнгать үзәге белән берлектә яңа ForteBank Kulanshi ArtSpace галереясын ача. Биредә банкның үз коллекциясендәге картиналар тәкъдим ителә. Ул, нигездә, Казахстан Республикасының хәзерге заман тасвирый сәнгате әсәрләреннән тора. Шунысы игътибарга лаек: коллекциядәге картиналарның күбесен банк чит илләрдән сатып алган һәм Казахстанга – әлеге җәүһәрләрнең авторлары туган һәм иҗат иткән илгә кире кайтарган. ForteBank алга таба да Казахстанның гаҗәеп бай мәдәни мирасын үстерү һәм саклауны инвестицияләвен дәвам итәчәк [2: 1].

2008 елда Астана шәһәрендә «Хас Санат» шәхси сәнгать галереясы ачыла. Галерея директоры Жанна Енсебаева ел саен Казахстан рәссамнары картиналарыннан «Алтын гасыр» күчмә күргәзмәсен оештыра, ул чит ил тамашачысын казах тасвирый сәнгате белән таныштыра. Республика башкаласында халыкта тасвирый сәнгать белән кызыксыну уятуда «Куланши» һәм «Хас санат» галереяларының өлеше гаять зур.

Казахстан Республикасы Милли музееның хәзерге заман сәнгатенә багышланган заллары башкала мәдәни тормышын формалаштыру өлкәсендә яңа зур мөмкинлекләр тудыра. 2018 елның 9 февралендә Астана шәһәрендә Алмагөл Менлибаеваның «Green, yellow, red and green» күргәзмәсе вернисажы белән яңа TSE art destination, 2020 елда Астанада «SAL seri» галереялары ачылды. Соңгысы актив сәнгатьчә-күргәзмә эшчәнлеге алып бара, «EXPO 2020 Dubai» форумын үткәргәндә Казахстан программасында катнаша.

***8. Хосусый компанияләр һәм сәнгать меценатлары ачкан галереялар***

Меценат-филантроплар инициативасы белән ачылган галереяларга иң ачык мисалларның берсе – «Алма-Ата» арт-үзәге галереясы. 2003 елда эшмәкәр, Казахстан меценатлары клубы әгъзасы һәм учредителе, «Астана моторс» һәм «Mega Center» компанияләре башлыгы Нурлан Смагулов әлеге «Алма-Ата» арт-үзәген булдыра. Аның коллекциясе Казахстан рәссамнарының иң яхшы әсәрләреннән туплана.

Музей фондына казах һәм чит ил осталарының 700 сәнгать әсәре керә. Программаның сәнгатьчә стратегиясе һәм концепциясе музейның сәнгать җитәкчесе Меруерт Калиева тарафыннан эшләнә. Үзенең эшен музей ике күргәзмә – Н. Смагуловның шәхси коллекциясендәге әсәрләрдән төзелгән «Қонақтар» экспозициясе һәм Казахстан рәссамы Алмагөл Менлибаева иҗатының «Мин барысын да аңлыйм» ретроспективасы белән башлап җибәрә. Беренче катта иркен күргәзмә

мәйданнары, шул исәптән «Ұлы дала» һәм «Сарыарқа» заллары урнашкан. Үзәк зал Чарын каньонының табигый характерын чагылдырган art Street атриумына бирелгән. Шунда ук музей фондларын саклау урыны, реставрация остаханәсе һәм «Шеберхан» креатив киңлеге урын алган.

***9. Индивидуаль рәссамнар ачкан галереялар***

Иң ачык мисалларның берсе – 2011 елда танылган рәссам Анара Абжанова тарафыннан ачылган «Anara» сәнгать галереясы.

***10. Казахстан милләтләре сәнгате галереялары***

Казахстанда яшәүче милләтләрнең берсе – уйгурлар сәнгате «Duniya Art» галереясында тәкъдим ителә. Ул уйгур рәссамнары иҗатын берләштерә. Галерея 2008 елда Республика уйгур музыкаль комедия театрында, хәзерге заман сәнгате галереясы буларак, тамашачыларны уйгур мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру максаты белән ачыла. 1990 елларда ук уйгур рәссамнары иҗтимагый берләшмә төзиләр, «Duniya Art» галереясы элегрәк «Мын ой» исемен йөртә.

***11. Иҗади инициативалар өчен мультифункцияле арт-платформалар***

Галереяларның эше арт-базар (ул, үз чиратында, максатчан аудиториянең социаль-психологик факторларына нигезләнә) законнары буенча гына бармый, ә яңа мәгънәләр эзләүне дә максат итә. Бу галереялар иҗади инициативалар өчен күппрофильле характердагы мәйданчыклар кебек, анда галерея китапханә, арт-киңлек, кафе, арт-шоп, пресс-клуб, белем бирү курслары, рәсем ясарга өйрәтү дәресләре һ. б. белән берләштерелергә мөмкин. Хәзерге заман сәнгатен үстерү буенча коммерцияле булмаган оешмага нигез салучы, Artios арт-агентлыгы директоры Динә Байтасова (Астана), Aspan Gallery (Алматы) җитәкчесе Меруерт Калиева, Kazarian Art Center (Алматы) җитәкчеләре Эдуард Казарян һәм Асия Хәсәнова, «Artmeken. Сәнгать территориясе» киңлеге (Алматы) җитәкчеләренең берсе Гәүһәр Сатпаева, «Art Lane» (Алматы) җитәкчесе Айне Зөбәйер, «Art Future» сәнгать һәм мәдәният үзәге директоры Тогжан Сакбаеваларның эшчәнлекләре – шуның матур үрнәге.

Казахстанда галерея эшчәнлеге мәдәниятнең дәрәҗәсен күтәрүгә йогынты ясый һәм сәнгать әсәрләрен сатуның цивилизацияле формаларын булдырырга ярдәм итә. Инфраструктура буларак арт-базар оештыру – катлаулы процесс, ул галерея эшен үстерү белән генә бәйле түгел.

Шуңа да карамастан, уңышлы эшләп килүче сәнгать галереялары рәссам белән потенциаль сатып алучылар арасында арадашчы ролен үтиләр.

Казахстанда сәнгать галереялары ачылу динамикасын анализлау өчен, аларның барлыкка килү тарихын таблица рәвешендә карыйк.

1 нче таблица.

Казахстанда сәнгать галереялары ачылу хронологиясе
(Алматы ш., Астана ш.)

| № | Галереяның исеме | Төзелгән елы | Шәһәр |
|---|---|---|---|
| 1. | Казахстан Рәссамнар берлегенең Үзәк күргәзмәләр залы | 1991 | Алматы |
| 2. | Рәссамнар йорты вернисажы | 1991 | Алматы |
| 3. | ДХВ – А. Кастеев исемендәге ДСМның күргәзмәләр залы | 1991 | Алматы |
| 4. | «Онер» салон-кибете | 1991 | Алматы |
| 5. | «Инкар» галереясы | 1992 | Алматы |
| 6. | «Ретро» | 1992 | Алматы |
| 7. | «Тәңре- Умай» | 1992 | Алматы |
| 8. | «Око» | 1992 | Алматы |
| 9. | «Уласу-Арт» | 1992 | Алматы |
| 10. | Азат Акимбекның «Шәрык антиквариаты» | 1993 | Алматы |
| 11. | «Улар» | 1993 | Алматы |
| 12. | «Вояджер» | 1993 | Алматы |
| 13. | «Рух» | 1993 | Алматы |
| 14. | «Мын-Ой» | 1993 | Алматы |
| 15. | «ARK» | 1997 | Алматы |
| 16. | «Рысбек Ахметов», хәзер «ArtSpace» | 1997 | Алматы |
| 17. | «Трибуна» | 1998 | Алматы |
| 18. | «Ою» | 1998 | Алматы |
| 19. | «Шежире» | 2001 | Алматы |
| 20. | «Антик М» | 2001 | Алматы |
| 21. | Ж. Шарденов исемендәге «Умай» сәнгать музее | 2002 | Алматы |
| 22. | «Адем-ай Plus» | 2002 | Алматы |
| 23. | «Хас Санат» | 2003 | Астана |
| 24. | «Art+decor» | 2004 | Алматы |
| 25. | Абылхан Кастеевның Сәнгать галереясы | 2004 | Жаркент |
| 26. | «Алма-Ата Арт» | 2005 | Алматы |
| 27. | «Вернисаж» | 2006 | Алматы |
| 28. | «Kulanshi» Хәзерге заман сәнгате үзәге | 2006 | Астана |
| 29. | «Arvest» | 2007 | Алматы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30. | «Duniya Art» | 2008 | Алматы |
| 31. | «Гулидина» | 2009 | Астана |
| 32. | «Брендлар галереясы» | 2009 | Алматы |
| 33. | «Ак рояль» | 2010 | Алматы |
| 34. | «Artfoglio» | 2010 | Алматы |
| 35. | «A la prima» | 2011 | Алматы |
| 36. | «Номад» | 2011 | Алматы |
| 37. | «AnarA» Сәнгать галереясы | 2011 | Алматы |
| 38. | Укучылар сарае галереясы | 2011 | Астана |
| 39. | «Джамаль» ориенталь сәнгать арт-галереясы | 2012 | Алматы |
| 40. | «Ару-арт» | 2012 | Алматы |
| 41. | Укучылар сарае галереясы | 2012 | Алматы |
| 42. | «ASSIA» | 2013 | Алматы |
| 43. | «Clay House Gallery» | 2013 | Алматы |
| 44. | Artumar | 2013 | Астана |
| 45. | «Бакчасарай» | 2014 | Алматы |
| 46. | «Жаухар» арт-галереясы | 2014 | Алматы |
| 47. | «360 space Multimedia» | 2014 | Алматы |
| 48. | «Aspan Gallery» | 2015 | Алматы |
| 49. | «Art Hall Gazeeff» | 2015 | Алматы |
| 50. | «Esentai gallery» | 2015 | Алматы |
| 51. | «Kazarian Art center» | 2015 | Алматы |
| 52. | «Miras» | 2015 | Астана |
| 53. | «Forte Bank Kulanshi Art Space» | 2016 | Астана |
| 54. | Art Future Сәнгать һәм мәдәният үзәге | 2017 | Алматы |
| 55. | «Artmeken. Сәнгать территориясе» | 2017 | Алматы |
| 56. | «Art lane» | 2017 | Алматы |
| 57. | «TSE art destination» | 2018 | Астана |
| 58. | «Almaty Gallery» | 2018 | Алматы |
| 59. | «Art Galaxy Alma-Ata» | 2019 | Алматы |
| 60. | «Sal Seri» | 2020 | Астана |
| 61. | «Efes Art Space» | 2022 | Алматы |
| 62. | «Aizakhan Gallery» | 2025 | Астана |
| 63. | «LM Kulanshi Art» | 2025 | Астана |
| 64. | «Целинный» Хәзерге заман мәдәнияте үзәге | 2025 | Алматы |
| 65. | «Хәзерге заман сәнгате музее Almaty Museum of Arts» | 2025 | Алматы |

Әлеге галереяларның кайберләре инде ябылган, әмма шуңа да карамастан Казахстанда галерея һәм күргәзмә эшен оештыруга алар үз өлешләрен керттеләр. Галерея һәм музейларның ачылу вакыты буенча статистик мәгълүматларны өйрәнү шуны күрсәтә: ел саен 1–5 галерея һәм күргәзмә мәйданчыклары стабиль рәвештә ачылып тора. Танылган сәнгать белгече В. Ибраева болай дип яза: «25 лет – период, который принято считать поколенческим. Сегодня на казахстанский арт-рынок приходит новая генерация игроков, имеющая представление о мировых стандартах и создавшая ряд пространств нового типа. Учитывая существование старых галерей, небольшого аукциона, все большее участие современных казахстанских художников в международных проектах и, как следствие, повышение цен на их работы, появление новых арт-пространств в Казахстане – свидетельство динамичного развития этого рынка» [7].

Алматы һәм Астана шәһәрләрендә генә дә 60–70 кә якын галереяның ачылуы һәм эшләве сәнгать галереяларын хәзерге Казахстанның социаль-мәдәни күренеше итеп карарга мөмкинлек бирә. Алар бер юнәлештә генә эшләми. Казахстанда аларның 11 төре бар. Бүген медиа, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм социаль челтәрләрнең мөмкинлекләреннән файдалану нәтиҗәсендә, күп кенә галереялар массакүләм коммуникацияләр пространствосында мультифункцияле арт-платформалар булып тора. Галереялар һәрвакыт реципиент (тамашачы) белән рәссам арасында коммуникатор булып, арадашчы ролен үтәгәннәр. Казахстанда галеристлар мәдәни-агарту эшчәнлеге алып баралар, шулай ук девелоперлар, проектчылар эшен дә башкаралар.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклап әйтәсе килә: тамашачыларның тасвирый сәнгать белән кызыксынуларын арттыруда, республикада һәм чит илләрдә Казахстан рәссамнары иҗатын популярлаштыруда сәнгать галереялары һәм музейларның роле гаять зур. Музей һәм галереялар эшчәнлегенең төп максаты – коммерция юнәлешеннән тыш, потенциаль тамашачыларны һәм сатып алучыларны югары сәнгатькә тарту һәм Казахстан тасвирый сәнгатен бөтендөнья мәдәни киңлегендә берләштерү.

**Әдәбият**

1. В Алматы откроется музей современного искусства Almaty Museum of Arts // Tengrinews. URL: https://tengrinews.kz/kazakhstan_news/almatyi-otkroetsya-muzey-sovremennogo-iskusstva-almaty-580384 (дата обращения: 03.10.2015).

2. В головном офисе открылась художественная галерея. URL: https://forbes.kz/life/afisha/v_golovnom_ofise_fortebank_otkryilas_hudojestvennaya_galereya/ (дата обращения: 12.10. 2025).

3. В сентябре в Алматы открылись центр и частный музей современного искусства. URL://https://delartemagazine.com/news/v-sentyabre-v-almaty-otkrylis-centr-i-chastnyj-muzej-sovremennogo-iskusstva/ (дата обращения: 09.2025).

4. *Ибраева В.* Как меняется арт-рынок Казахстана спустя четверть века своего существования. URL: https://forbes.kz/articles/novoe_pokolenie_2 (дата обращения: 09.04.2018).

5. *Карцева Е. А.* Выставочное и галерейное дело. М.: Директ Паблишинг, 2019. 195 с.

6. *Салмина А.* Музей современного искусства площадью больше 10 тыс. кв. м заработал в Алматы. Чем удивляет коллекция? // «МИР 24». URL: https://mir24.tv/news/16645962/muzej-sovremennogo-iskusstva-ploshadyu-bolshe-10-tysyach-kv.-metrov-zarabotal-v-almaty.-chem-udivlyaet-kollekciya (дата обращения: 12.10. 2025).

7. *Суворов Н.Н.* Галерейное дело. Обращение произведений искусства. СПб.: Лань: Планета музыки, 2024. 288 с.

8. *Фомичев В.И.* Выставочное дело: учебник для среднего профессионального образования. 2-е изд., перераб. и доп. М.: Юрайт, 2025. 134 с.

9. Целинный попал на обложку старейшего архитектурного издания в мире // Курсив. Lifastyle. URL: https://kz.kursiv.media/2025-10-02/ozmn-celinnyi-popal-na-oblozhku-stareishego-arhitekturnogo-izdaniya-v-mire/?utm_campaign=endless_feed (дата обращения: 02.10.2025).

***Мухтарова Гайни Сейсен кызы,***
*фәлсәфә фәннәре кандидаты, профессор, Күләш Байсәетова исемендәге Казах милли сәнгать университетының «Сценография һәм декоратив сәнгать» кафедрасы мөдире, Казахстан Рәссамнар берлеге әгъзасы (Астана шәһәре, Казахстан Республикасы)*

***Могильная Анастасия Валерьевна,***
*педагогика фәннәре кандидаты, доцент, Күләш Байсәетова исемендәге Казах милли сәнгать университетының «Сценография һәм декоратив сәнгать» кафедрасы мөдире, Казахстан Рәссамнар берлеге әгъзасы (Астана шәһәре, Казахстан Республикасы)*

***Смагулов Арыстан Серикбол улы,***
*Күләш Байсәетова исемендәге Казах милли сәнгать университетының сәнгать факультеты деканы, Казахстан Рәссамнар берлеге әгъзасы (Астана шәһәре, Казахстан Республикасы)*

***Мухтарова Гайни Сейсеновна,***
*кандидат философских наук, профессор, заведующий кафедрой «Сценография и декоративное искусство» Казахского Национального университета искусств имени Куляш Байсеитовой, член Союза художников Казахстана (г. Астана, Республика Казахстан)*
*gaini.mukhtarova2022@gmail.com;*

***Могильная Анастасия Валерьевна,***
*кандидат педагогических наук, доцент, заведующий кафедрой «Сценография и декоративное искусство» Казахского Национального университета искусств имени Куляш Байсеитовой, член Союза художников Казахстана (г. Астана, Республика Казахстан)*
*yatsan_m@mail.ru;*

***Смагулов Арыстан Серикболович,***
*декан художественного факультета Казахского Национального университета искусств имени Куляш Байсеитовой, член Союза художников Казахстана (г. Астана, Республика Казахстан)*
*smagulovarystan7@gmail.com*